# Мәктәп хәбәрчесе

№2

ноябрь
2018 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

**/ Мөхәррир сүзе /**

## 29 ноябрь – Әниләр көне

Хөрмәтле кардәшләр! Гәзитебезнең бу саны барыбыз өчен дә иң олы зат булган Әниләребезгә багышлана. Бервакыт, шундый вакыйгага юлыктым: бер хатын, кечкенә баласын җитәкләп, юлдан бара. Баласы сокны эчеп бетергәч, савытын юл өстенә ташлады. Әнисе савытны аягы белән юл кырыена этеп куйды. Шунда бу хатынга күзәтеп торучы бер бабай, шаккатып, әйтте: "Ана мени бу?!". Хатынның аңламаган йөзен күреп :"Баласын тәртипкә өйрәтмәгән ана – ана түгел ул", - диде.

Тарихка күз салсак та, ата-ананы олылау һәр чорга да хас булган. Изге китабыбыз булган Коръәндә әти-әнигә мәрхәмәт Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү белән янәшә китерелә ("Локман" с., 14 а.). Мөхәммәт пәйгамбәрдән (с.г.с.) "Җәннәт кайда?" дип сорагач, **"Җәннәт - әниләрегезнең аяк астында"** – дип җавап биргән. Борынгы әкиятләрдә әниләрен караудан баш тарткан балаларның төрле җәнлекләргә әверелүе турында сөйләнелә. Хәзерге чор әдәбиятында да күп кенә язучылар анага рәхмәтле булу проблемасын күтәрә. Моңа мисал итеп Әмирхан Еникиның "Әйтелмәгән васыять", Туфан Миңнуллиның "Әниләр һәм бәбиләр", Муса Җәлилнең "Ана бәйрәме", Рәшидә Җиһаншинаның "Улларым" әсәрләрен китерү дә җитә.

Әйе, баланы дөньяга китерү, төнге йокыларын калдырып аны карау, һичшиксез, бик авыр. Ләкин, ата-ананың баласына карата төп бурычы – аңа күркәм тәрбия бирү. Шул уңайдан, редколлегия әгъзалары белән **"Бала тәрбияләүнең максаты нидә?"** – дигән темага әниләрдән сорашу үткәрдек. Сорашуда катнашкан әниләрнең барысы да **бала тәрбияләүнең төп максаты – тәрбияле, әхлаклы, кешелекле бала үстерү** дип саный. Барчасы да үз балаларының җәмгыятькә файдалы, туганнарын хөрмәт итүче, нәселнең дәвамчысы булуын, киләчәктә ата-анасын каравын телиләр.

Хөрмәтле әниләр! Барыгызга да балалар һәм оныкларыгызны тәрбияләрлек саулык-сәламәтлек, ана бәхете телибез. Балаларыгыз турында "Бу – минем улым (кызым)!" дип, горурланып әйтергә насыйп булсын!

***Мөхәррир Гөлчәчәк Шәмәрдәнова***

## Әниләр өчен конкурс!

Хөрмәтле әниләр! **"Бала тәрбияләүдә актуаль проблема"** дигән темага мәкаләләр конкурсы игълан итәбез! Иншада бер яисә берничә актуаль проблеманы тасвирлап, аларга үзегезнең чишелеш юлларыгызны язсагыз була. Җиңүчене һәм катнашучыларны приз көтә!

**/ Укучылар иҗаты /**




## Әни диеп язып куйдым...

***(Иншалардан өзекләр)***

Әни кеше безне алга ,яктылыкка этәрә. Безгә дөньяның серләрен ача. Әниләр безнең өчен ут йота."Җәннәт-әни аягы төбендә"-дигән бит. Чыннан да бит шулай. Алар безнең сәламәт булуыбызны, үзебезне бәхетле тоюыбызны тели. Әни кадерен белеп, һәрчак әнигә булышып яшик.

Әниемнең кочагы,
Изгелекләр учагы,
Балам, диеп, назлап, сөеп
Ярат, ярат син тагы.

***Виктория Нукина. VII сыйныф***


"Әни"-, дип әйткәндә күңелгә наз тула. Әнине күргәч, янына чабып килеп, аны кочаклап аласы килә. Ул без кайгырган вакытта юата белә. Безне тәрбияләде, ашатты, үстерде, һәрвакытта булышып торды. Әнине кадерләргә, тыңларга кирәк. Әнисез калсак, без гомеребезне күз алдыбызга да китерә алмыйбыз. Аны беркем дә алыштыра алмый. Орышса да, әнкәебез безне яратып орыша.

Яратыгыз газиз әниләрне.
Алар да бит сезне ярата.
Авыр булган чакта кулын сузып,
Тәмле теле белән юата.

***Әминә Туктамышева. VII сыйныф***

## / Мәктәп яңалыклары /

**13 ноябрь** – ата-аналар җыелышы үткәрелде. Җыелышта, гадәти көн тәртибеннән тыш, Аксубай муниципаль районы полициясенең өлкән лейтенанты, ЮХИДИ хезмәткәре Сибгатуллин Илшат Ришат улы да чыгыш ясады. Ул әти-әниләргә балаларны төрле юл һәлакәтләреннән саклау турында сөйләде, юл хәрәкәте иминлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирде.




**19, 22, 26 ноябрь** – мәктәп укучылары география, математика, биология фәннәре буенча уздырылган олимпиадаларның муниципаль турында катнаштылар.

**23 ноябрь** – Аксубай сәнгать мәктәбенә йөрүче укучылардан Самат Гафиятуллин, Ләйсән Закирова, Кәүсәр һәм Сара Насыйровалар Иске Кармәт авылындагы Хәсән Туфан музеенда уздырылган кичәдә катнаштылар. Әлеге чара шул авылда туып үскән ветеран укытучы Равил Сәлиевнның "Өметнең чиге юк" исемле китабын тәкъдим итүгә багышланган иде.




**28 ноябрь** – "Әниләр көне" уңаеннан мәктәптә төрле чаралар уздырылды. Бу чараларда аеруча башлангыч сыйныфлар активлык күрсәтте. Алар әниләргә багышланган рәсемнәр күргәзмәсе һәм әдәби монтаж күрсәттеләр. Бәйрәмнең икенче өлешендә балалар һәм әниләр катнашында "Җырлыйк әле" уены уйнатылды. Өлкән һәм урта сыйныфлар арасында "Әни" темасына иншалар конкурсы игълан ителсә дә, бу чарада, ни сәбәпледер, VII сыйныфның кайбер укучылары гына катнаштылар.

## / Өлкәннәр киңәше /

### *Ана күңеле – балада*

Хөрмәтле әниләр! Барыбызга да билгеле булганча, бала тәрбияләү иң катлаулы һәм җаваплы эшләрдән санала. Әгәр без бүгенге көндә балаларга гомумкешелек кануннарын, әхлак кагыйдәләрен сеңдермәсәк, киләчәктә урамнарыбыз буйлап нинди җан ияләре йөриячәк?

Балаларыбызның мәрхәмәтле, ярдәмчел, тырыш, җаваплы, ышанычлы, акыллы, түзем һ.б. күркәм сыйфатларга ия булганын кайсыбыз теләми? Бармы икән шундый әти-әниләр?... Юктыр, мөгаен. Ләкин иң элек без үзебез шушы сыйфатларга ияме яки үзебезне тәрбияләү өстендә ниләр эшлибез? Балалар бөтен нәрсәне бездән күчерә. Аның өчен әти-әни иң дөрес үрнәк булып санала.

Гаиләдә без нинди сүзләр сөйлибез, өлкәннәрне ничек хөрмәт итәбез, балага өй эшләрен эшләргә булышабызмы, - болар барысы да кечкенә затның күңел сандыгына тупланып бара. Ә кичке ял вакытларын гаиләдә ничек үткәрәбез? Китаплар укыйбызмы, телевизор карыйбызмы, кул эшләре тотабызмы, әллә балаларыбыз каршында үзебезнең бар кимчелекләребезне онытып, башкаларның гайбәтен сөйләп утырабызмы? Төрле гыйбрәтле, тәрбияви вакыйгалар, хикәятләр сөйлибезме, догалар өйрәнәбезме, әллә һәр кич җыелышып бала күңелен үстерә торган файдалы уеннар уйныйбызмы? Әлеге үрнәк булу юллары мине шактый тирән уйга алып керә.

Шулай ук тормыш тәҗрибәмдә сыналган башка тәрбия ысуллары белән дә уртаклашасым килә:

- Бала тәрбиясендә, белем бирүендә катнашкан һәрбер кеше һичшиксез **абруйлы** булырга тиеш! (үзен олыларча тота белгән, җаваплы, үз сүзендә нык булган)

- Баланы ниндидер өстенлекләре өчен түгел, ә аның **булганы өчен яратырга** кирәк!

- Бала белән аралашкан бар очракта да **ачык йөзле, ярсымаган, йомшак тавышлы** булырга!

- Чиктән ашкан гаепләүләр, сәбәбен дә аңлатмыйча тыюлар, артык кырыслык – бу **дөрес булмаган тәрбияләү** ысулы!

- Бала уенчыклар белән уйнаганда кычкырып җибәрсә, уенчыгына ачуланса, тавышланып уйнаса, аны **тыймагыз**! (Бу психологлар теле белән **«сәламәт бушану»** дип атала. Кечкенә затның да күңелендә авыр, уңайсыз мизгелләр була. Ләкин күп вакыт аны өлкәннәр аңламый. Үзенең бу халәтеннән уңай юл белән котыла алмаган бала киреләнә, тыңламый, әйбер вата, башка балаларга ташлана)

- Балага үзен **начар итеп тоярга ирек бирмәскә** кирәк!

Сүземне имам әл-Газали сүзләре белән тәмамлыйсы килә: "Бел, башка эшләр белән беррәттән, балалар тәрбияләү иң мөһим, иң төп эшләрнең берсе. Балалар – Аллаһ тарафыннан ата-анага вакытлыча тапшырылган амәнәт, шул амәнәт өчен алар Аллаһының каршында хисап тотачаклар".

***Бакча төркеме тәрбиячесе Гөлүсә Насыйрова***

## / Котлыйбыз! /

Ноябрь аенда бакча төркеменнән **Нурматова Асия**, IV сыйныфтан **Хайруллин Айназ,** V сыйныфтан **Гафиятуллин Самат,** VIII сыйныфтан **Ахметова Нәзирә, Насыйрова Сара,** X сыйныфтан **– Сафиуллина Динәнең** туган көннәре булып узды. Кадерле дуслар! Сезне туган көннәрегез белән тәбрик итәбез! Сезгә тән һәм рух сәламәтлеге, тәртипле, тырыш, уңган шәхесләр булып үсүегезне телибез!

/ Чал тарихта эзле без /

## Милли мәгариф тарихында мәдрәсә дәвере

**1917 елга кадәр безнең татар халкы тормышында дин һәм мәгариф, мәчет һәм мәктәп бер-берсеннән аерылгысыз саналган.** Имамнар дини эшләрне оештыру белән беррәттән балаларга белем бирү, ягъни мөгаллимлек вазифасын да башкарган. Мәчете һәм мулласы булган авылда һичшиксез мәктәпләр эшләп килгән. Укыту өчен махсус бина булмаган очракта, балаларны мулла өендә булса да сабакка өйрәткәннәр.

**Революциягә кадәрге татар милли мәгариф системасы ике баскычлы укыту тәртибенә нигезләнгән.** Беренче баскычка караган уку йорты – мәктәп, башлангыч белем бирүне тәэмин иткән. Икенче баскычны, хәзерге исәп буенча, урта белем бирүче уку йортына торырлык мәдрәсәләр тәшкил иткән. Мәктәпләрдә гадәттә малайлар гына белем алган. Алар 6-7 яшьтән укырга йөри башлаган һәм өлгереш дәрәҗәсенә карап, 3-5 ел дәвамында укыганнар. Кыз балалар һәм мәктәп яшенә җитмәгән кечерәк малайлар, мәктәптә урын җитмәгән очракларда, остазбикәләр өенә йөреп дәрес алганнар. Мәктәптә кече яшьтәге балаларга сабак бирүне "сабиан" дип аталучы укытучылар алып барган. Мәктәпнең укыту программасы гарәп әлифбасы нигезендә укырга-язарга өйрәнү, "Иман шарты", Корьәннең җиденче өлеше – "һәфтияк"не ятлау, хисаб (арифметика), пәйгамбәрләр тарихы һәм әдәплелек буенча төрле китапларны өйрәнүдән гыйбарәт булган. Мәктәпләрдә укыту дәрес тәртибендә алып барылмаган. **Мөгаллим һәр укучы белән аерым шөгылләнгән.** Бер китапны өйрәнеп яки ятлап бетермичә торып, башкасына күчергә рөхсәт ителмәгән. Гадәттә иң башта төрки-татар телендәге китапларны өйрәнеп, алардан соң гарәпчәләргә күчкәннәр.

**Мәдрәсәләр, мәктәпләр белән чагыштырганда, укыту программасының катлаулыгы һәм уку вакытының 7-8 ел дәвам итүе белән аерылып торган.** Аларда мәктәптә үтелә торган фәннәрдән тыш фикһ (ислам юриспруденциясе), гарәп-фарсы телләре һәм әдәбияты, кәләм һ. б. заманасы өчен кирәкле саналган фәннәр укытылган. Мәдрәсә ачу авылда зур белемле мөдәррис яки шундый кешене читтән чакырып китереп, матди яктан тәэмин итеп торырлык байлар яшәгәндә генә мөмкин булган. Мәдрәсәләр сирәк булганлыктан, аларда читтән килгән шәкертләр дә укыган. Бу очракта мәдрәсә бинасы аларның тору урынына әверелгән. Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган шәкертләр укуларын чит илләрдәге югары уку йортларында дәвам иткәннәр, яки имамчылык итү хокукы алып, туган җирләрендә калганнар.

/ Күренекле шәхесләр /

## Майнадан юл алган җитәкче



1965 елның 1 сентябре. Бу көнне Түбән Майна тарихына алтын хәрефләр белән язылырлык вакыйга була – авылда сигезъеллык мәктәп ачыла. Мәктәпнең беренче директоры итеп яңа гына Казан педагогия институтын тәмамлаган **Насыйбуллин Рифкать Габдрахман улы** куела. Рифкать абый тумышы белән Норлат районына кергән Кычытканлы авылыннан. Аның әбисе Кычытканлыга Түбән Майнадан төшкән килен була. Сигезъеллык мәктәпнең ныклап аякка басып эшләп китүендә Рифкать абыйның өлеше бик зур. Ул эшләгән дәвердә авылга белемле педагогик кадрлар кайта. Мәктәпнең матди базасы ныгый, кабинетлар заманча укыту әсбаплары белән тәэмин ителә. Шул эшләре өчен авыл халкы Рифкать абыйны хәзер дә аны олы ихтирам белән искә ала.

Түбән Майнада ике ел эшләү дәверендә өметле җитәкче буларак танылган яшь директор, 1967 елның көзендә Алексеевск мәгариф бүлегенә күчерелә. Ул урында берничә ел эшләгәннән соң, Рифкать абый Татарстан Мәгариф министрлыгына чакырылып, лаеклы ялга киткәнче, шул югары оешмада гомуми бүлек мөдире вазифасын башкарды. Шулай итеп, хезмәт эшчәнлегенең тәүге адымнарын Майна җирендә башлап җибәргән яшь укытучыга, мәгариф өлкәсенең барлык баскычларын да уңышлы үтәргә насыйп булды. Безнең мәктәпкә урта мәктәп статусы алуда Рифкать абыйның ярдәме зур булды.

Пенсиягә чыкканнан соң Рифкать абый җәмәгать тормышыннан читләшмәде. Тагын ун ел дәвамында Татарстан мөселманнарының дини идарәсендә бүлек мөдире булып эшләде.

/ Күңелле тәнәфес /

### Мәктәп мәзәкләре

Малай кроссворд чишеп утыра:
- Ансыз пешерсәң, ризык тәмсез була. Өч хәреф. Әзрәк уйлагач, "әни" дип язып куя.

---------------------------------------------------------------------------

Әнисенең туган көнендә, ашаганнан соң , малае:
- Әнием, үзеңнең туган көнеңдә савыт-сабаны юма инде, калдыр......Иртәгә юарсың!

### Ребусны чишеп, табышмакның җавабын табыгыз



## *Фән олимпиадаларының муниципаль туры*

**Математика** фәне буенча 22 ноябрь көнне уздырылган олимпиадада XI сыйныф укучысы **Магизов Ильфир** 1 нче урынны, VIII сыйныф укучысы **Әхмәтова Нәзирә** 2 нче урыннарны яуладылар. (Укытучылары – **Хәсәнова Ризидә Хәсән кызы**) Нәзирә шулай ук биология фәне буенча да 2 нче урынны алды. (Укытучысы – **Гафиятуллина Руфия Әмир кызы**)

## *Спорт ярышлары*



Ноябрь ае көрәшчеләребезнең яңа җиңүләре белән башланып китте. Айның беренче көнендә Әлки районы спорт мәктәбе призына 2005-2007 елгы яшүсмерләр арасында уздырылган **билбау көрәше буенча Республика турнирында** VII сыйныф укучылары **Камалов Илдус** белән **Хәбибрахманов Ильяс** үз авырлыкларында 3 урыннарны алдылар. 24 ноябрь көнне егетләребез Алексеевск бистәсендә Дәүләт Думасы депутаты И.Н.Хәйруллин призына уздырылган **билбау көрәше буенча Республика турнирында** көч сынаштылар. Бу ярышта **Камалов Илдус** – 1, **Хәбибрахманов Ильяс** – 2, **Нурматов Халит** – 3 урыннарны яуладылар. (Тренерлары – **Камалов Илһам Илгизәр улы**)



Көзге каникул көннәрендә безнең мәктәп укучылары Халит Нурматов, Айназ һәм Данил Хәйруллиннар “Авыл таңнары” гәзите призына уздырыла торган **XXIII шахмат турнирында** катнаштылар. Ярыш нәтиҗәләре буенча **Хәйруллин Данил** 3 урынга ия булды.

## *Дәрестән тыш эшчәнлек*

Ноябрь аенда уздырылган “Слово – это источник счастья” **Бөтенроссия иншалар конкурсының муниципаль этабында** катнашып, VII сыйныф укучысы **Сафиуллина Зөлфирә** 3 дәрәҗә грамота белән бүләкләнде. (Укытучысы – **Кадыйрова Гөлнур Габделхак кызы**)

“Үз кулларыбыз белән могҗиза” дип исемләнгән декоратив-гамәли иҗат буенча район конкурсында катнашып, **изоҗеп** номинациясендә **Сафиуллина Зөлфирә** – 1, **кинусайга** номинациясендә **Нукина Вика** – 2 урыннарны алдылар. (Остазлары – **Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**)

---



## *Мәдәни көндәлек*

**Күп кенә гәзит укучыларны башлангыч сыйныф укучыларына таратылган Мәдәни көндәлек алып бару тәртибе кызыксындыра. Шул мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап, без башлангыч сыйныф укытучысы Хәйруллина Рузилә апаларына мөрәҗәгать иттек.**

- Менә берничә ел инде Республика күләмендә **“Укучының мәдәни көндәлеге”** дип исемләнгән бәйге үткәрелеп килә. Безнең мәктәп укучылары да әлеге чарада бик теләп катнашалар. Бәйгенең шарты: катнашучы никадәр күбрәк мәдәни урыннарда була, җиңү ихтималы шулкадәр күбрәк.



“Укучының мәдәни көндәлеге” балалар һәм аларның әти-әниләрен рухи яктан баету, Ватан һәм милләтенә мәхәббәт, үз илендә яшәүче халыкларның мәдәниятен, тарихын өйрәнү, әти-әни һәм бала мөнәсәбәтләрен якынайту кебек матур максатларга нигезләнә. Көндәлектә бу максатларны тормышка ашыру юллары төсле рәсемнәр аша балаларны үзенә җәлеп итә. Музей, театр, галерея кебек үзәкләрнең ничек төзелешен башта бала көндәлектә таныша.

Бәйге 2 этаптан тора. Беренчесе 2018 елның 1сентябреннән алып 17 декабрьгә кадәр дәвам итә. Бу этапта катнашу өчен махсус сайтта теркәлеп, шунда укучы барган урыннар турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш. Җиңүчеләр “Презедент чыршысы” бәйрәменә чакыру билеты алачак.

Икенче этап 2019 елның 1 гыйнварыннан 15 маена кадәр дәвам итәчәк. Бәйгенең ахырында нәтиҗәләргә йомгак ясалгач, җиңүчеләрне тантаналы бүләкләү көтә.

Безнең мәктәп укучылары арасыннан бүгенге көнгә **Насыйрова Кәүсәр** алда бара. Башка укучыларны да аңардан калышмаска чакырабыз.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Гөлчәчәк Шәмәрданова
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова